СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

31.05.2019 Алабуга шәһәре № 374

2013 елның 7 февралендәге 292 санда чыккан «Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, контроль-хисап органы рәисе, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланылган затларның хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны каплау һәм күләмнәре тәртибе турында»гы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының карарына үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 25 июнендә чыккан 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 27 маддәсе, Алабуга муниципаль районы Уставының 32 маддәсе нигезендә һәм киләчәктә бюджет акчаларын рациональ куллануга юнәлдерелгән эшне дәвам итү максатларында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. 2013 елның 7 февралендәге 292 санында чыккан «Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, контроль-хисап органы рәисе, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланылган затларның хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны каплау һәм күләмнәре тәртибе турында»гы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карар преамбуласында «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында «Татарстан Республикасы Законының 21 маддәсе белән» сүзләрен «2013 елның 25 июнендә чыккан 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 27 маддәсе белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланылган затларны, контроль-хисап органы рәисен, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.3 пунктында «б) калган муниципаль хезмәткәрләргә – бер бүлмәле (бер урынлы)